ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

К А Р А Р

№ 22 Ютазы ав. «12» сентябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2011 елның 13 апрелендәге 7 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрларын алып бару тәртибе турында»гы карарны үз көчен югалткан дип тану хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2023 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында»гы 1-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2016 елның 30 мартындагы 13 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрларын алып бару тәртибе турындагы нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы 2021 елның 20 декабрендәге килешү нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы авыл җирлеге Советының 2011 елның 13 апрелендәге карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрларын алып бару тәртибе турында»гы 7 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре порталы составында

«Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Н.Ф.Җәләев

